**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СИМӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫНЫҢ IV ЧАКЫРЫЛЫШ XLIV УТЫРЫШЫ**

Симәк авылы. 28 май 2024 ел

# КАРАР № 70

**Физик затларның җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, «Росси Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзида турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Закон «Региональ салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтүгә ышанычсыз дип тануны өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2024 елның 12 апрелендәге 18-ТРЗ номерл Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципа районы __Симәк___ авыл җирлеге Советы **КАРАР БИРДЕ:**

1. Физик затларның җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтү ышанычсыз дип тануга өстәмә нигезләр билгеләргә:

1) варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас ачылганн соң бер ел эчендә мирасны кабул итмәгән очракта үлгән яки үлгән дип игълан ителгән физ затларда бурычлар булу;

2) 2024 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдән чыгарылган җирле салымнар буен оешмаларга яки шәхси эшмәкәрләргә исәпләнгән бурычлар булу;

3) физик затларның Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясын билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң 500 сумнан артмаган суммада бурычы булу.

2. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Симәк авыл җирле Советының 2023 елның «18» маендагы 53 номерлы «Җирле салымнар суммалары өлешен бурычларны түләтүгә ышанычсыз дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» карарын гамәлдән чыгарырга.

3. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районы Симәк авыл җирлегенең «Интерне мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында игълан итәргә һәм «Татарст Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.R урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә һәм 2024 елны гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз көчен җәелдерә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Мөслим муниципаль районы
Симәк авыл җирлеге башлыгы Р.Ә.Садертдинов